СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАР**

**25 октябрь 2021 ел** **№ 5**

**Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Югары Масра авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Югары Масра авылында Югары Масра авылы, Калинин урамы, 14А йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябренә 08 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Югары Масра авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Калинин урамында 19 нчы йорттан Г.Гафиятуллин урамының 1 нче йортка кадәр водоотводный торбалар урнаштыру белән юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю;

- урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру;

- зират коймасын ремонтлау һәм буяу өчен материаллар сатып алу;
-зират территориясендә инвентарьлар саклау өчен бина урнаштыру,материаллар сатып алу;

- зиратны карап тоту өчен бензин триммеры (бензокосилка) сатып алу;

- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь эленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

3. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Югары Масра авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Масра авылы, Калинин урамы, 14А йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин